ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.09.2018 г.Мензелинск № 1086

2017/2018 уку елында ТР ДОСААФ белем бирү учреждениеләрендә белгечләр әзерләү нәтиҗәләре һәм 2018/2019 уку елына бурычлар турында

1998 елда кабул ителгән “Хәрби бурычлар һәм хәрби хезмәт турында”гы №53-ФЗ Федераль законы таләпләрен, 1999 елда кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турындагы Положениене раслау турында”гы №1441 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 27.09.2017 елда кабул ителгән №727 Карарын һәм Татарстан Республикасы хәрби комиссариаты билгеләгән план-заданиене үтәү өчен гражданнарны хәрби-учет белгечлекләренә әзерләү заданиесе 95,83% ка үтәлгән.

Укытуның беренче агымында хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерләнгән 5 кешенең барысы да (100%) шул юнәлештә Кораллы Көчләргә җибәрелде. Белгечләрне ВУС-837 буенча билгеләнгән заданиене үтәү өчен җитмешмәгән көчләр халык хуҗалыгында “С” категориясе алган гражданнар хисабыннан башкарылды.

2018 елда чакырылырга тиешле гражданнар исәбеннән белгечләрне үз вакытында һәм сыйфатлы әзерләү максатларында,

**КАРАР ЧЫГАРАМ:**

1. 2018/2019 уку елына хезмәткә чакырылучы гражданнар исәбеннән белгечләр әзерләү буенча төп чаралар планын расларга (Кушымта №1).
2. 2018/2019 уку елына белгечләр әзерләүне оештыру һәм уздыруны югары дәрәҗәдә тәэмин итү буенча төп чаралар планын расларга (Кушымта №2).
3. Хәрби-учет белгечлекләре буенча гражданнарны әзерләү өчен гражданнарны сайлау буенча комиссия составын расларга (Кушымта №3).

4.Минзәлә районының хәрби комиссарына (Владимиров С.А.) Минзәлә муниципаль район территориясендә яшәүче, армия хезмәтенә чакырылырга тиешле гражданнар арасында ТР ДОСААФының өч уку йортына әзерлек алып барырга:

- “С” категорияле транспорт чараларын эксплуатацияләү буенча белгечләр (ВУС №837) – ТР ДОСААФының Минзәлә автомәктәбендә;
- тәгәрмәчле БТР-80 йөртүче белгечләр (ВУС №124) – ТР ДОСААФының Түбән Кама автомәктәбе;
- укчы-парашютист белгечләрен (ВУС №100) - Россия ДОСААФының Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубында (Коркачы);

5. Минзәлә районы хәрби комиссарына (Владимиров С.А.) производстводан аерылып сбор җыю юлы аша, әзерлек укудан аерылмыйча уздырыла торган Россия ДОСААФының Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубында (ТР ДОСААФының Минзәлә автомәктәбендә укучылардан тыш) белгечләр әзерләүне тәкъдим итү;

6. Оешма һәм учреждение җитәкчеләренә укуга җәлеп ителгән гражданнарның эш урыннарын даими эш урынында уртача хезмәт хакын түләргә һәм РФ Хөкүмәтенең 2004 елда кабул ителгән №704 карары нигезендә чыгымнарны түләргә;

7. Минзәлә районы хәрби комиссарына (Владимиров С.А.) оешмалар һәм учреждениеләр күтәргән чыгымнарны компенсацияләүне РФ Хөкүмәтенең 2004 елда кабул ителгән №704 карары нигезендә башкаруны тәкъдим итәргә. Оешмаларга һәм гражданнарга күрсәтелгән чыгымнарны түләтүне белгечләр әзерләү белән бәйле чыгымнарны компенсацияләүгә Федераль казначылык аша кергән акчалар исәбеннән һәм тиешле документларны теркәп исәп-хисап ясалганнан соң бер ай эчендә башкарырга;

8. Оешма һәм белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә ТР ДОСААФ белем бирү учреждениеләрендә дәресләргә даими йөрү өчен армия хезмәтенә чакырылучыларга тиешле шартлар тудырырга, аларның дәресләргә йөрешен һәм өлгерешен даими төстә контрольдә тотуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә;

9."Минзәлә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ДКУга билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган, вакытлыча эшләмәүче армия хезмәтенә чакырылучылар арасыннан гражданнарны хәрби-учет белгечлекләренә әзерләүне оештыруны тәкъдим итәргә;

10. ТР ДОСААФының Минзәлә автомәктәбе начальнигына (Исмәгыйлов Т.Г.) ТР Минзәлә муниципаль районының "Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге" МКУ (Хәмидуллин Р.И.) белән берлектә курсантлар белән физик әзерлек буенча дәресләр оештыруны тәкъдим итәргә;

- ТР ДОСААФының Минзәлә автомәктәбе начальнигына (Исмәгыйлов Т.Г.) дәресләр башлану алдыннан тулысынча укыту-матди базасын әзерләргә, укыту процессын камилләштерү буенча даими эш алып барырга, әзерлекне һәм инструктор-укытучылар составының дәресләр уздыруын контрольдә тотуны көчәйтергә.

11. Минзәлә районының хәрби комиссарына (Владимиров С.А.) РФ Кораллы Көчләре өчен белгечләр әзерләү барышы турында Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенә даими рәвештә мәгълүмат бирүне тәкъдим итәргә. 2017-2018 уку елына РФ Кораллы Көчләре өчен белгечләр әзерләү планының үтәлеш барышы турында хәрби комиссар мәгълүматын укытуның беренче агымын әзерләү нәтиҗәләре буенча – апрельдә, уку елы нәтиҗәләре буенча – сентябрь аенда тыңларга;

12. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Н.Г.Бикеевага йөкләргә.

Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазифаларын башкаручы А.Г.Гатина.

Кушымта №1
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты Карарына
№1086 «__» 24.09. 2018 ел

**2018/2019 уку елына белгечләр әзерләү буенча төп чаралар**
**П Л А Н Ы**

| № п/п | Чаралар | башкаручы | Башкару сроклары | Башкару турында билге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Укучы яшьләрне хәрби-учет белгечлекләренә өйрәтүгә оештыру һәм хәрби-һөнәри ориентация уздыру мәсьәләләре буенча инструктор-методик дәресләр уздыру, тормыш иминлеге нигезләре укытучылары-оештыручыларга, психологларга, урта мәктәп һәм урта махсус белем бирүче уку йортлары укытучыларына консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү. | Минзәлә район хәрби комиссариаты | 10.09 кадәр | |
| 2. | ТР ДОСААФ белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре, районның гомумбелем учреждениеләре җитәкчеләре катнашында ТР ДОСААФ белем бирү учреждениеләрендә белем алу өчен кандидатлар сайлау мәсьләсе буенча методик-инструкторлык дәресләре уздыру. | Минзәлә район хәрби комиссариаты | 10.09 кадәр | |
| 3. | Хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерлек өчен кандидатлар сайлау | Минзәлә район хәрби комиссариаты | 20.09 кадәр | |
| 4. | Хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерлек өчен укытуга юнәлтелгән гражданнарга медицина тикшерүе уздыру | Минзәлә район хәрби комиссариаты | 20.09 кадәр | |
| 5. | Хәрби-учет белгечлекләре буенча әзерлек өчен җаваплы вазифаи затлар белән укыту-методик җыелу (сбор) уздыру | Минзәлә район хәрби комиссариаты | 01.10 кадәр | |
| 6. | Уку төркемнәрен комплектлау | Минзәлә район хәрби комиссариаты | 01.10 кадәр | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7. | Курсантларның дәресләргә йөреше һәм өлгереше турында предприятие (учреждение) һәм белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә мәгълүмат бирү | Минзәлә район хәрби комиссариаты | Укыту срогы дәвамында | |
| 8. | Хәрби-учет белгечләр әзерләү һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү мәсьәләләре буенча район уку йортларының җитәкчелек һәм укытучылар составы белән методик-укыту җыелуларын (сбор) уздыруда катнашу | Минзәлә район хәрби комиссариаты<br>ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбе начальнигы | 01.10 кадәр | |
| 9. | ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбенең укыту-матди базасын камилләштерү | ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбе начальнигы | даими | |
| 10. | Район гомумбелем учреждениеләренең укыту-матди базасы торышын һәм хәрби техника белән коралланышын һәм оператив идарәгә тапшырылган мөлкәтнең торышын контрольдә тоту | Минзәлә район хәрби комиссариаты | даими | |
| 11. | ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбе өчен укытучылар составы һәм укыту-производство мастерлары вазифаларына кандидатлар сайлау | Минзәлә район хәрби комиссариаты<br>ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбе начальнигы | даими | |
| 12 | ТР ДОСААФы белем бирү учреждениеләрендә укытуны уздыру:<br>**<u>Укытуның 1 нче агымы</u>**:<br>1.ВУС №837 белгечлеге буенча:<br>ТР ДОСААФының Минзәлә автомәктәбе – “С” категорияле машина йөртүче -10 кеше.<br>2.ВУС №124 белгечлеге буенча:<br>ТР ДОСААФының Түбән Кама автомәктәбе - тәгәрмәчле БТР-80 йөртүчеләр – 1кеше.<br>3.ВУС №100 белгечлеге буенча:<br>Россия ДОСААФының ТР Үзәк аэроклубы - парашютчы -2 кеше.<br>**<u>Укытуның 2 нче агымы</u>**: | ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбе начальнигы<br>-<br>-<br>- | октябрь-февраль<br>апрель<br>март-июнь<br>сентябрь | |
| | 1.ВУС №124 белгечлеге буенча:<br>ТР ДОСААФының Түбән Кама автомәктәбе - тәгәрмәчле БТР-80 йөртүчеләр – 1кеше.<br>2.ВУС №100 белгечлеге буенча:<br>Россия ДОСААФының ТР Үзәк аэроклубы - парашютчы -2 кеше. | - | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13. | ТР ДОСААФының Минзәлә автомәктәбендә чыгарылыш имтиханнарын уздыру:<br>**Укытуның 1 нче агымы:**<br>**Укытуның 2 нче агымы:** | Минзәлә район хәрби комиссариаты<br>ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбе начальнигы | февраль<br>июль | |
| 14. | ТР ДОСААФының Минзәлә автомәктәбендә өлешчә һәм комплекслы тикшерүләр уздыруда хәрби комиссариат вәкилләренең катнашуы (ТР, Минзәлә муниципаль районы) | Минзәлә район хәрби комиссариаты | тикшерүләр барышында | |

Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты
җитәкчесе урынбасары

Н.Г.Бикеева.

Кушымта №2
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе
Карарына
№1086 дата «24» 09 2018 ел

**Хәрби-учет белгечлекләре буенча гражданнарны әзерләүне уздыру һәм югары дәрәҗәдә оештыруны тәэмин итү буенча төп чаралар Планы**

| № п/п | Чаралар | Башкару сроклары | Башкаручы | Башкару турында билге |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Курсантларны коралланыш һәм РФ Кораллы Көчләре коралланауында булган хәрби техника белән таныштыру. Хәрби хезмәт узу шартларын җиткерү. | октябрь апрель | Минзәлә район хәрби комиссариаты | |
| 2 | ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбенең матди-техник базасы белән курсантларны таныштыру | октябрь апрель | ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбе начальнигы | |
| 3 | Укыту взводларында курсантлар белән "РФның һәр гражданинының изге бурычы буларак Ватанны саклау һәм хәрби хезмәткә чакырылыштан баш тарткан өчен гражданнарның җаваплылыгы турында" һәм "Бөек Ватан сугышы тарихы" темаларына әңгәмәләр уздыру | октябрь март | Минзәлә район хәрби комиссариаты ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбе начальнигы | |
| 4 | ТР ДОСААФының Минзәлә автомәктәбе курсантлары арасында хәрби-учет белгечлеген иң яхшы белүчегә ярышлар уздыру | гыйнвар июль | ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбе начальнигы | |
| 5 | "Ватанны саклаучылар көне" һәм "Бөек Җиңү көне"нә багышланган тантаналы чаралар уздыру | февраль май | Минзәлә район хәрби комиссариаты ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбе начальнигы | |
| 6 | Бөек Ватан сугышы ветераннары һзм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар (ветераннар) белән очрашулар уздыру | февраль | Минзәлә район хәрби комиссариаты ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбе начальнигы | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7 | Запастагы офицерлар һәм район хәрби комиссариат бүлеге катнашында “Ватанны саклау дигән һөнәр бар” тематик кичәсен оештыру һәм уздыру. | февраль май | Минзәлә район хәрби комиссариаты, ДОСААФның Минзәлә автомәктәбе начальнигы | |
| 8 | Тантаналы чаралар уздыру, чыгарылыш укучыларын хәрби хезмәткә җибәрүгә багышланган чаралар уздыру. | октябрь апрель | Район хакимияте, Минзәлә район хәрби комиссариаты, ДОСААФның Минзәлә автомәктәбе начальнигы | |
| 9 | Хәрби дан көннәрен уздыру | Хәрби дан көннәре вакытында | ДОСААФның Минзәлә автомәктәбе начальнигы | |
| 10 | ТР ДОСААФының Минзәлә автомәктәбенең чыгарылыш укучылары хезмәт иткән хәрби частьләр белән хәбәрләшү, хат алышу | даими | ДОСААФның Минзәлә автомәктәбе начальнигы | |
| 11 | Хәрби-патриотик берләшмәләр һәм хәрби-патриотик юнәлештәге клублар белән үзара аралашуны оештыру | даими | Минзәлә район хәрби комиссариаты, ДОСААФның Минзәлә автомәктәбе начальнигы | |
| 12 | Хәрби-гамәли күп ярышлар (многоборье) буенча укыту оешмаларында: кросс (чаңгы ярышлары), кул гранаталарын ыргыту, каршылык полосаларын узу, автомобиль йөртү буенча ярышлар уздырырга. | даими | Район хакимияте, Минзәлә район хәрби комиссариаты, ДОСААФның Минзәлә автомәктәбе начальнигы | |
| 13 | ТР ДОСААФының Минзәлә автомәктәбендә әзерлек узганнар арасыннан хәрби хезмәттә булган хәрбиләр турында очеркларны матбугатта бастыру өчен материаллар әзерләү. | Укыту чоры дәвамында | Минзәлә район хәрби комиссариаты, “Минзәлә” газетасы редакциясе. | |

Минзәлә муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.Г.Бикеева

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МЕНЗЕЛИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОГРН 1061682000080
р 06 92/09
Исполнительный комитет Мензелинского муниципального района
ИНН 1628006341

Кушымта №3
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе
Карарына

№ 1086 «24» 09 2018 ел.

**Хәрби-учет белгечлекләре буенча гражданнарны әзерләү өчен гражданнарны сайлау буенча комиссия**

**СОСТАВЫ**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Владимиров С.А | | Минзәлә районының хәрби комиссары, комиссия рәисе |
| 2. | Исмәгыйлов Т.Г. | | ТР ДОСААФ, Минзәлә автомобиль мәктәбе начальнигы, комиссия рәисе урынбасары |
| *Комиссия әгъзалары:* | | | |
| 3. | Каюмов И.И. | | Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының бүлекчә начальнигы (гражданнарны хәрби хезмәткә чакыру һәм әзерләү) |
| 4. | Гыйлемов Ф.Ф. | | ТР ДОСААФы Минзәлә автомәктәбе начальнигының укыту-производство эше буенча урынбасары |
| 5. | Миңнәхмәтова Л.Н. | | Минзәлә муниципаль районының “Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” МКУ баш белгече |
| 6. | Хәбибуллин М.С. | | табиб, медицина комиссиясе эше белән җитәкчелек итүче, Минзәлә район үзәк хастаханәсенең табиб-терапевты |
| 7. | Никитин А.Е. | | Минзәлә муниципаль район башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге” МКУ методисты |

Минзәлә муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.Г.Бикеева

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ * РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МЕНЗЕЛИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН 1061682000036 р 06 92/09 Исполнительный комитет Мензелинского муниципального района ИНН 1628006341